**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре №111-18 «18» апрель 2017 ел

Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2014 елның 10 апрелендәге 292-42 номерлы «Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексы, Азнакай муниципаль районы уставы, Азнакай муниципаль районы составына керүче җирлекләрнең җирле үзидарә органнарында вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә карый торган вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервын формалаштыру буенча үзара хезмәттәшлекне оештыру турында төзелгән Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмә нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай район Советының 2014 елның 10 апрелендәге 292-42 номерлы «Азнакай муниципаль районында муниципаль хезмәт вазыйфаларының югары һәм баш төркемнәренә караган вакантлы идарәчел вазыйфаларны һәм вазыйфаларны биләүгә кадрлар резервы турында» карарына үзгәрешләрне кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Рәис М.З.Шәйдуллин